| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 ноябрь 2022 ел Буа шәһәре № 1-37

Буа муниципаль районында «Буа» сәнәгать
парκы идарәче компаниясе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14-15 статьясы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Индустриаль (сәнәгать) парклары һәм идарәче компанияләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 04 августындагы 794 номерлы карары, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә икътисадның эшкәртү, яңа продукция җитештерү, продукциянең яңа төрләрен үстерү, аеруча прогрессив технологияләрне һәм җитештерүне кертү, эш урыннары булдыру максатларында, Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы, Буа районы, Карлы авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, космик эшчәнлекне, оборона җирләрен, куркынычсызлыкны һәм башка махсус билгеләнештәге җирләрне тәэмин итү өчен сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре категориясенә караган, 16:14:140102:366 кадастр номерлы гомуми мәйданы 162786 кв. м., 16:14:140102:409 кадастр номерлы гомуми мәйданы 5500 кв.м., 16:14:140102:395 кадастр номерлы гомуми мәйданы 27144 кв.м., 16:14:140102:396 кадастр номерлы гомуми мәйданы 12762 кв.м., 16:14:140102:397 кадастр номерлы гомуми мәйданы 21026 кв.м., 16:14:140102:422 кадастр номерлы гомуми мәйданы 9322 кв.м., 16:14:140102:421 кадастр номерлы гомуми мәйданы 13000 кв.м., 16:14:140102:416 кадастр номерлы гомуми мәйданы 9460 кв.м., 16:14:140102:407 кадастр номерлы гомуми мәйданы 5050 кв.м., 16:14:140102:408 кадастр номерлы гомуми мәйданы 965 кв.м., 16:14:140102:382 кадастр номерлы гомуми мәйданы 2182 кв.м., 16:14:140102:420 кадастр номерлы гомуми мәйданы 340 кв.м җир кишәрлекләрендә урнашкан, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә

«Буа» сәнәгать паркын төзү турында» Буа муниципаль районы Советының 2017 елның 13 октябрендәге 2-25 номерлы карары белән төзелгән, «Буа» сәнәгать паркы идарәче компаниясе вәкаләтләрен генераль директор М.Х. Шакиров йөзендә «УНИПАРК» ҖЧЖ компаниясенә йөкләргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Советының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов